

Барлык халык белән бергә Мордовия моселманнары да Ураза гаетын бәйрәм итте. Рузаевка районы башлыгы Александр Борисович Юткин моселманнарны изге Рамазан аенын тәмамлануын билгеләп vтvче Ураза бәйрәме белән котлады. Ул Татар Пешләсендәге Жәмигъ мәчетендә иртәнге намаз алдыннан дин тотучыларга морәжәгать итте.
- Сезне чын кvнелдән һәм ихластан Ураза бәйрәме белән котлыйм. Ул кешеләрнен әхлакый камиллеккә, шәфкатьлелеккә һәм рухилыкка омтылышын гәvдәләндерә. Мин сезнен якыныгызга һәрвакыт ярдәм итv момкинлегегез булуын телим. Авылыгызны, кече ватаныгызны vстерv очен эшләгәннәрегез очен рәхмәт әйтәсем килә. Без бер милләт, бергә, кулга-кул тотынышып барабыз.      Сезнен топ бәйрәмегездә булу минем очен зур хормәт! Бvген сезнен кvбегез махсус хәрби операция уздыру зонасында Жинvне якынайта. Ә сез монда гуманитар ярдәм жыясыз, фронтка ярдәм итәсез, шулай ук безнен уртак жинvебезне оештырасыз! Мин сезгә монын очен рәхмәт белдерәм! Бәйрәм белән, кадерле дуслар! Сезгә һәм гаиләләрегезгә бәхет, тынычлык, игелек, иминлек һәм сәламәтлек телим! - диде Александр Борисович.
Жыелучыларны шулай ук Татар Пешлә авыл жирлеге администрациясе башлыгы Ринат Дәвлюк улы Шабаев котлады:
- Рамазан аенда безгә Коръән китабы индерелде. Без бу айны хормәт итәбез, шуна кvрә мин бvген барлык моселманнарны, авыл халкын олы бәйрәм белән котлыйм!
Тиздән без Жинvнен 80 еллыгын билгеләп vтәчәкбез. Боек Ватан сугышы елларында 400дән артык авыл кешесе яу кырларында һәлак булды. Без аларны һәрвакыт истә тотачакбыз. Хәтер мәнгелек булсын очен, тиздән һәйкәлебезне тозекләндерv башланачак. Бvлеп бирелгән акчалар очен район администрациясенә рәхмәт, ә безнен гражданнарга – хезмәтләре белән ярдәм иткәннәре очен рәхмәт.
Аннары район башлыгы Югары Урледимгә юл тотты. Бирелдә яшәvчеләр авыл читенә жыелып, барысы бергә «Айнулла» мәчетенә юл тоталар. Юлда дога укыйлар. Александр Борисович Юткин барысын да сәламләде һәм бәйрәм белән котлады! Шулай ук ул хәбәр иткәнчә, быел Палаевкада балалар һәм спорт мәйданчыклары тозеләчәк. Палаевка-Урледим авыл жирлеге башлыгы Рифат Рафик улы Рахмуков район житәкчесенә авыл пробле-маларына игътибары һәм моселманнар очен моһим булган Ураза бәйрәмендә котлаулары очен рәхмәт белдергән.
Зубово-Поляна районы Горенка авылы халкы Ураза бәйрәмебезне хормәт итеп каршылаганнар. Менә рәсемдә (Горенка мәктәбе сайтыннан алынды) Рәсимжан улы Мясум белән Вәлиулла кызы Зульфия Чукашкиннар, мәчеткә йори торган оныклары Артур, Алиса, Аделина Шлаевлар белән олы Гаетыбызны бәйрәм иткәннәр. Алар милли мәдәния-тыбызны, әдәбиятыбызны, динебезне яраталар.

**Наилә НАСЫРОВА** *әзерләде*